**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

09.12.2022 № 389

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагында фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме төзергә.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 09 » декабрендәге
389 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) – фәнни-технологик үсеш буенча тәкъдимнәр әзерләү, әлеге өлкәдә чаралар эшләү һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советына тиешле тәкъдимнәр бирү өчен төзелгән даими эшли торган коллегиаль орган.

1.2. Эш төркеме Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Эш төркеменең бурычлары

2.1. Эш төркеменең төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) дәүләт сәясәтенең фәнни-технологик үсеш өлкәсендәге төп юнәлешләрен эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашучыларның хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру өчен аларның үзара килешенгән гамәлләр кылуын тәэмин итү;

б) дәүләт сәясәтенең фәнни-технологик үсеш өлкәсендәге төп юнәлешләрен эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашучылар эшчәнлеген камилләштерү, шулай ук әлеге өлкәдә хокукый җайга салуны камилләштерү чараларын эшләү;

в) Татарстан Республикасы территориясендә фәнни-технологик үсеш өлкәсендәге дәүләт программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыру планнарының үтәлеше барышын карап тикшерү;

г) түбәндәге тәкъдимнәрне карап тикшерү:

фәнни-технологик үсеш өлкәсендәге стратегияләрне, программалар һәм проектларны гамәлгә ашыру буенча;

фәнни-тикшеренү һәм проект инфраструктурасын үстерү буенча;

инновация һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлекләренең өстенлекле юнәлешләре буенча;

фәнни-технологик үсеш өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруның финанс модельләре буенча;

д) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советына карауга Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше өлкәсендә тәкъдимнәр бирү.

## III. Эш төркеменең хокуклары

3.1. Эш төркеме аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

а) үзенең утырышларына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, фән, мәгариф оешмалары һәм башка оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары вәкилләрен, Татарстан Республикасы территориясендә фәнни-технологик үсеш өлкәсендәге дәүләт программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыруда башка катнашучыларны чакырырга һәм аларның хисапларын тыңларга;

б) дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, фән, мәгариф оешмаларыннан һәм башка оешмалардан, иҗтимагый берләшмәләрдән эш төркеме эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

в) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, фән, мәгариф оешмалары һәм башка оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен билгеләнгән тәртиптә эш төркеме уздыра торган чараларда катнашуга җәлеп итәргә;

г) эш төркеменә йөкләнгән аерым бурычларны хәл итү белән бәйле рәвештә ярдәмче төркемнәр, шул исәптән эксперт төркемнәре оештырырга.

## IV. Эш төркеме эшчәнлеген оештыру

4.1. Эш төркем составын Татарстан Республикасы Президенты раслый.

4.2. Эш төркеме аның составына төркем эшчәнлегендә җәмәгать башлангычларында катнашучы эш төркеме җитәкчесен, аның урынбасарларын, эш төркеме секретарен һәм әгъзаларын кертеп оештырыла.

4.3. Эш төркеме үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм аның утырышларында кабул ителә һәм эш төркеме җитәкчесе тарафыннан раслана торган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

4.4. Эш төркеме утырышын эш төркеме җитәкчесе, ә ул булмаганда эш төркеме җитәкчесе йөкләве буенча эш төркеме җитәкчесе урынбасарларының берсе уздыра.

4.5. Эш төркеме секретаре:

а) эш төркеме утырышларында шәхсән катнаша;

б) эш төркеме әгъзаларына эш төркеме утырышы уздырылачак көнгә кимендә биш көн кала утырышны уздыру урыны, көне, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен тарата;

в) эш төркеме утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларны әзерли.

4.6. Эш төркеме әгъзалары:

а) эш төркеме утырышларында шәхсән катнашалар;

б) эш төркеменә йөкләнгән аерым бурычларны хәл итү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куялар;

в) эш төркеме караларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыралар.

4.7. Эш төркеме утырышлары ихтыяҗ туган саен, әмма кимендә кварталга бер тапкыр уздырыла.

4.8. Эш төркеме утырышлары турыдан-туры катнашу рәвешендә яисә видеоконференция режимында уздырылырга мөмкин.

4.9. Эш төркеме утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, эш йөртергә хокуклы дип санала. Эш төркеме әгъзасы утырышка килмәгән очракта, аның карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә бирергә хакы бар.

4.10. Эш төркеме карарлары ачык тавыш бирү рәвешендә кабул ителә һәм утырышта катнашучы эш төркеме әгъзаларның яртысыннан артыгы аны яклап тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Эш төркеме әгъзаларының тавышы тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.11. Эш төркеме карарлары утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, аларга эш төркеме секретаре кул куя һәм рәислек итүче раслый.

4.12. Эш төркеме эшчәнлеген оештыру ягыннан Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәэмин итә.

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 09 » декабрендәге
389 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе |
| Гыйльметдинов<br>Альберт Харис улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Миңнеханов<br>Рифкать Нургали улы | Цифрлы нигездә үсешкә ярдәм күрсәтү ассоциациясе Советы рәисе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Поминов<br>Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, эш төркеме секретаре |
| Әбҗәлилова<br>Ләйсән Рәхим кызы | «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Әдһәмова<br>Юдия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Гарипов<br>Альберт Шамил улы | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Залаков<br>Наил Ринат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |
| Калачев<br>Алексей Алексеевич | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Камалов<br>Рөстәм Илдар улы | «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры ярдәмчесе |
| Карпов<br>Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Колчин<br>Иван Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Кудряшев<br>Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Миңнебаев<br>Марат Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Никонов<br>Тимур Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Савельев<br>Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе |
| Сәлахов<br>Мәкъзүм Хәлимулла улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Сафиуллин<br>Марат Рәшит улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисадый тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Таюрский<br>Дмитрий Альбертович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе беренче проректоры – фәнни эшчәнлек буенча проректоры (килешү буенча) |
| Фатыйхов<br>Илдар Разин улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Һидиятуллин<br>Рөстәм Илдар улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары |
| Шакиров<br>Динар Рафикъ улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |

___________